БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25 февраль 2022 ел № 111

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.4 статьясына туры китереп, Татарстан Республикасы Балтач районы Прокуратурасының 2021 елның 13 июлендәге 02-01-22-21 номерлы мәгълүмат хаты нигезендә, Балтач район Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының 2018 елның 28 мартындагы 118 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Текст буенча «2006 елның 2 июнендәге «ФСК ЕЭС» ААҖнең техник сәясәте турында нигезләмәләр» сүзтезмәсен «2012 елның 14 декабрендәге «ФСК ЕЭС» ААҖнең техник сәясәте турында нигезләмәләр» сүзтезмәсенә алмаштырырга;

1.2. 5 статьяның 5.1 пунктындагы 5.1.2 пунктчасында «ПБ 12-529-03 «Газ бүлү һәм газ куллану системаларының куркынычсызлыгы кагыйдәләре»» сүзтезмәсен «Ростехнадзорның 2020 елның 15 декабрендәге 531 номерлы боерыгы белән расланган ФНП «Газ бүлү һәм газ куллану системаларының куркынычсызлыгы кагыйдәләре»» нә алмаштырырга;

1.3. «СП 42.13330.2011 Актуальләштерелгән редакциясе СНиП 2.07.01-89*. «Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү»» сүзтезмәсен текст буенча «СП 42.13330.2016 Актуальләштерелгән редакциясе СНиП 2.07.01-89 «Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү» гә алмаштырырга;

1.4. 5 статьяның 5.3 пунктындагы 5.3.1 пунктчасында «СанПиН 2.4.1.2660-10 «Мәктәпкәчә оешмаларның төзелешенә, аларны тотуга һәм аларның эш режимын оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр», «СанПиН 2.4.2.2821-10 «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем бирү шартларына һәм аны оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр» сүзтезмәләрен «СП 2.4.3648-20 Балаларны һәм яшьләрне тәрбияләү, укыту, ял итү һәм

сәламәтләндерү оешмаларына карата санитар-эпидемиологик таләпләр»енә алмаштырырга;

1.5. 5 статьяның 5.4 пунктындагы 5.4.2 пунктчасында «СанПиН 2.1.3.2630-10 «Медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга санитар-эпидемиологик таләпләр» сүзтезмәсен «СП 2.1.3678-20 Бүлмәләрне, биналарны, корылмаларны, җиһазларны һәм транспортны эксплуатацияләүгә, шулай ук товарлар сатуны, эшләр башкаруны яки хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хуҗалык итүче субъектларның эшчәнлек шартларына карата санитар-эпидемиологик таләпләр» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 5 статьяның 5.5 пунктындагы 5.5.6 пунктчасында «СН 461-74 «Элемтә линияләре өчен җирләрне бүлеп бирү нормативлары» дигән сүзтезмәне «0,38-750 кВ көчәнешле электр челтәрләре өчен җир бүлеп бирү нормалары» 14278 тм-т1 номерлы ведомство төзелеш нормалары»на алмаштырырга (1994 елның 20 маенда Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының электр энергетикасы департаменты раслаган);

1.7. 5 стаьяның 5.9 пунктындагы 5.9.4 пунктчасында «Каты көнкүреш калдыклары өчен полигоннарны төзүгә һәм карап тотуга карата гигиеник таләпләр» сүзтезмәсен «СанПиН 2.1.3684-21 Шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрен тотуга, су объектларына, эчәр суларга һәм эчәр су белән тәэмин итүгә, атмосфера һавасына, туфракларга, торак биналарга, җитештерү, иҗтимагый биналарны эксплуатацияләүгә, санитар-эпидемиягә каршы (профилактик) чараларны оештыруга һәм үткәрүгә санитар-эпидемиологик таләпләр» сүзтезмәсенә алмаштырырга;

1.8. 5 статьяның 5.9 пунктындагы 5.9.6 пунктчасында «СанПиН 2.1.7.1322-03 Җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштыруга һәм зарарсызландыруга карата гигиеник таләпләр» сүзтезмәсен «СанПиН 2.1.3684-21 Шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрен тотуга, су объектларына, эчәр суларга һәм эчәр су белән тәэмин итүгә, атмосфера һавасына, туфракларга, торак биналарга, җитештерү, иҗтимагый биналарны эксплуатацияләүгә, санитар-эпидемиягә каршы (профилактик) чараларны оештыруга һәм үткәрүгә санитар-эпидемиологик таләпләр» сүзтезмәсенә алмаштырырга;

1.9. 5 статьяның 5.9 пунктындагы 5.9.6 пунктчасында «Токсинлы сәнәгать калдыкларын зарарсызландыру һәм күмү буенча полигоннар. 29. Проектлау буенча төп нигезләмәләр»» сүзтезмәсен ««СП 127.13330.2017 Токсинлы сәнәгать калдыкларын зарарсызландыру һәм күмү буенча полигоннар. Проектлау буенча төп нигезләмәләр»гә алмаштырырга;

1.10. 6 статьяның 6.1 пунктындагы 5 абзацта «2014 елга кадәр җәмәгать инфраструктурасы, соңиаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителешнең социаль гарантияләре дәрәҗәсен билгеләү турында» 2009 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (2013 елның 30 маендагы үзгәрешләр белән)» сүзтезмәсен «2014 елга кадәр җәмәгать инфраструктурасы, социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителешнең социаль гарантияләре дәрәҗәсен билгеләү турында» 2009 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

карары (2019 елның 28 августындагы үзгәрешләр белән)» сүзтезмәсенә алмаштырырга;

1.11. 6 статьяның 6.2 пунктындагы 3 абзацта «СССР Транспорт төзелеше министрлыгы тарафыннан расланган автобус тукталышларын проектлау буенча методик тәкъдимнәр» сүзтезмәсен «ОСТ 218.1.002-2003 Автомобиль юлларында автобус тукталышлары»на алмаштырырга. Гомуми техник таләпләр»;

1.12. «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1999 елның 19 октябрендәге 1683-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган Социаль инфраструктура объектларында Россия Федерациясе субъектларының норматив ихтыяҗларын билгеләү методикасы» сүзтезмәсен текст буенча төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин